**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2344**
**06.05.2022**

Башкарма комитетның «Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатында Яр Чаллы шәһәренең муниципаль предприятиеләренә, учреждениеләренә (оешмаларына) исемнәр бирү, аларның исемнәрен алмаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 8 июнендәге 3283 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатында Яр Чаллы шәһәренең муниципаль предприятиеләренә, учреждениеләренә (оешмаларына) исемнәр бирү, аларның исемнәрен алмаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 8 июнендәге 3283 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Исемен мәңгеләштерүгә тәкъдим ителә торган вакыйганың яки затның әһәмиятлелеген объектив бәяләү максатында предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) исеме мәңгеләштерелә торган зат вафат булганнан соң ярты ел узгач;

2) истәлеккә исеме бирелә торган вакыйга булганнан соң 10 ел узгач.

Әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацларындагы нигезләмәләр предприятиеләргә һәм учреждениеләргә Советлар Союзы Геройларының, Россия Федерациясе Геройларының, Социалистик Хезмәт Геройларының, Россия Федерациясе хезмәт Геройларының, Дан ордены белән бүләкләнгән гражданнарның, «Ватан каршындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнгән гражданнарның, «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнгән гражданнарның исемнәре бирелгән очракларга кагылмый.»;

2) 2 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия» һәм «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 6 маендагы
2344 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2018 елның 8 июнендәге
3283 номерлы карарына
2 нче кушымта

Күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турында материалларны карап тикшерү буенча
комиссия составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Хәлимов Рамил Мәрван улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 2. | Хуҗин Рөстәм Нияз улы | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы |
| 3. | Касыймова Рәхимә Равил кызы | комиссиянең җаваплы секретаре, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы урынбасары, оештыру-педагогик тәэмин итү һәм социаль яклау бүлеге башлыгы |
| комиссия әгъзалары: | | |
| 4. | Айкин Виктор Сидимирович | Яр Чаллы шәһәренең «76 нчы гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесенең югары квалификацион категорияле тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы (килешү буенча) |
| 5. | Видинеева Ләйсән Әлфит кызы | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| 6. | Иванова Венера Бәхтегәрәй кызы | Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы (килешү буенча) |
| 7. | Канеев Билял Абдрахман улы | «Яр Чаллы шәһәре тарихы музее» МАМУның һәйкәлләрне саклау буенча өлкән фәнни хезмәткәре (килешү буенча) |
| 8. | Кәрамиев Румил Рәүф улы | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| 9. | Мостафина Фәйрүзә Зөфәр кызы | мәгарифне үстерү мәсьәләләре буенча шәһәр Хакиме киңәшчесе, Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре, Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы (килешү буенча) |
| 10. | Насрединов Роман Мансур улы | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе башлыгы |

| | | |
|---|---|---|
| 11. | Рзаева Гөлзада Мөхәммәтгәрәй кызы | Татарстткан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы (килешү буенча) |
| 12. | Тарабукин Алексей Сергеевич | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| 13. | Хәбибуллин Фидәрис Фәндәвис улы | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| 14. | Харисов Винер Хәмит улы | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы |
| 15. | Хөсәенов Уел Галим улы | Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы (килешү буенча). |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева